ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.03.2019 ел Баулы шәһәре №61

Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль районы милке турындагы
мәгълүматны ачу турындагы
нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маенда кабул ителгән 327нче санлы «Татарстан Республикасы милке турындагы мәгълүматны ачу турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карары (2018 елның 22 сентябрендәге үзгәрешләр белән) нигезендә, муниципаль милекне нәтиҗәле һәм рациональ файдалану максатларында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы милке турындагы мәгълүматны ачу турындагы нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://bavly.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесенә йөкләргә.

Җитәкче И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының 2019 елның
12 мартында кабул ителгән
61нче санлы карары белән
РАСЛАНГАН

Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы милке турындагы
мәгълүматны ачу турындагы
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы милке турындагы мәгълүматны ачу турындагы нигезләмә «Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны яклау турында»гы 2006 елның 27 июлендә кабул ителгән 149-ФЗ номерлы, «Дәүләт милкен һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы 2001 елның 21 декабрендә кабул ителгән №178-ФЗ, «Муниципаль сер турында»гы 1993 елның 21 июлендә кабул ителгән №5485-1 санлы федераль законнар нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының муниципаль милке турындагы мәгълүмат составын, шулай ук аны ачу тәртибен һәм вакытын билгели.

1.2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының муниципаль милке турындагы мәгълүматны ачу дигәндә (алга таба – муниципаль милек) аның белән кызыксынучы барлык кешеләрнең дә аннан файдалана алуын тәэмин итү аңлашыла.

1.3. Исәпкә алына торган муниципаль милек объектлары турында мәгълүмат Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары, муниципаль норматив-хокукый актлар нигезендә “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы” МКУ тарафыннан бирелә. Соралган мәгълүматта дәүләт сере булганда, мәгълүмат бирүдән баш тарту мөмкин.

1.4. Юридик затларның мәнфәгатьләренә зыян китереп мәгълүмат куллану өчен Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында җавапка тарту каралган.

1.5. Муниципаль милек турындагы мәгълүмат Татарастан Республикасы Баулы муниципаль районы муниципаль милке реестрындагы, шулай ук Баулы

муниципаль районы милке булган җир участоклары турындагы мәгълүмат күләмендә бирелә.

1.6. Муниципаль милек турындагы мәгълүматны ачу мәгълүмат тарату һәм кызыксынган затларга мәгълүмат бирү рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Мәгълүмат тарату массакүләм мәгълүмат чараларында бастыру һәм «Интернет» челтәрендә сайтка урнаштыру аша гамәлгә ашырыла.

Мәгълүмат кызыксынган затларның язма мөрәҗәгатьләре буенча, шул исәптән аерым милек объектлары буенча да бирелә.

## 2. Мәгълүмат тарату

2.1. «Интернет» челтәрендә урнаштыру юлы белән таратыла торган муниципаль милек турында мәгълүмат түбәндәгеләрдән гыйбарәт (мондый мәгълүмат закон белән чикләнгән мәгълүматны үз эченә алган очраклардан тыш):

Баулы муниципаль районының муниципаль учреждениеләре исемлеге (атамасы, урнашу урыны);

Баулы муниципаль районының муниципаль унитар предприятиеләре исемлеге;

муниципаль казна предприятиеләре исемлеге (исеме, урнашу урыны);

устав капиталы өлеше (акцияләр пакетлары) Баулы муниципаль районы милке булган хуҗалык җәмгыятьләре исемлеге (хуҗалык җәмгыятенең атамасы, урыны, устав капиталында район өлеше);

Баулы муниципаль районы милкендәге күчемсез мөлкәт (биналар, бүлмәләр) исемлеге (атамасы, урнашу урыны, мәйданы, максатчан билгеләнеше, кулланылышы чикләнү, өченче затларның хокуклары йөкләнеше);

Баулы муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыруның прогноз планы (программасы);

Баулы муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыру прогноз планы (программасы) үтәлеше турында хисап.

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының муниципаль милке турында күрсәтелгән мәгълүмат шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыгарга мөмкин.

2.2. Әлеге Нигезләмәнең 2.1. пунктында күрсәтелгән белешмәләр Баулы муниципаль районының рәсми сайтында ел саен 1 гыйнварга булган хәлдә финанс елы тәмамланганнан соң дүрт айдан да соңга калмыйча басылып чыгарга тиеш.

2.3. Баулы муниципаль районы муниципаль милке булган объектлар турында мәгълүматны ачу хосусыйлаштыру турындагы законнар белән билгеләнгән күләмдә гамәлгә ашырыла.

3. Кызыксынган затларга мәгълүмат бирү

3.1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының муниципаль милке реестрында теркәлгән аерым милек объектлары буенча мәгълүмат кызыксынган затларга хат рәвешендә яисә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының муниципаль милке реестрыннан өземтә рәвешендә бирелә.

3.2. Исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат (яисә аны бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән карар) «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы" тарафыннан мөрәҗәгатьне теркәгән көннән алып 30 көн эчендә бирелә.

3.3. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының муниципаль милек реестрыннан өземтәләр түбәндәгеләргә бирелә:

исәпкә алу объектлары хуҗаларына яки аларның законлы вәкилләренә;

исәпкә алу объектына хокук иясеннән яки аның законлы вәкиленнән ышаныч кәгазе алган физик һәм юридик затларга;

Россия Федерациясе Хисап палатасы, Татарстан Республикасы Хисап палатасы, Баулы муниципаль районы Контроль-хисап палатасына;

җирле үзидарә органнарына һәм Татарстан Республикасы, Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт власте органнарына;

дәүләт хакимиятенең федераль органнарына, шул исәптән:

күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органнарга,

салым органнарына,

судларга, хокук саклау органнарына, исәпкә алу объектлары һәм (яки) аларга хокук ияләре белән бәйле эшләре булган суд приставларына-башкаручыларга,

Федераль монополиягә каршы органга һәм Татарстан Республикасында аның территориаль органына.

3.4. Әлеге нигезләмәнең 3.3. пунктында күрсәтелмәгән кызыксынган затларга бары тик исәпкә алу объектлары Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының муниципаль милек реестрында булу-булмау турында гына мәгълүмат бирелә.

3.5. Соратып алына торган мәгълүматны бирүдән баш тарту турындагы язмача җавап мотивацияләнергә тиеш.

Мәгълүмат бирүдән баш тартуга түбәндәге сәбәпләр нигез булып тора:

мөрәҗәгатьтә тарату законнар белән чикләнгән мәгълүматны үз эченә алган белешмәләр сорала;

мөрәҗәгать әлеге затны кызыксындырган объектны билгеләргә мөмкинлек бирми;

мөрәҗәгатьтә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының муниципаль милек реестрында булмаган мөлкәт объекты турында мәгълүмат күрсәтелсә.